Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

“08” октябрь 2020 ел

№ 12

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, шулай ук җирлек территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга, чисталыкка һәм тәртипкә карата бердәм таләпләр билгеләү, тулаем төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2017нче елның 7нче ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында»гы 34 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Шәһәр җирлеге территориясен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм җыештыру буенча эшләрнең үтәлешен, билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында, Саба шәһәр җирлеге башлыгы җитәкчелегендәге вәкаләтле орган тарафыннан контрольдә тота».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында яктыртырга:

- Татарстан Республикасы, Саба районы, Урта Саба авылы, Тукай урамы, 33 нче йорт ( авыл клубы);

- Саба шәһәр җирлеге бинасында: Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы бистәсе, Мәктәп урамы, 31А йорт;

- Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы бистәсе, З.Йосыпов урамы.

Җирлек башлыгы Р.М. Хәсәнов